РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Исполнительный комитет поселка городского типа Уруссу Ютазинского муниципального района**
423950, п.г.т. Уруссу
ул. Пушкина, 38
тел. 2-61-50 2-92-40

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Ютазы муниципаль районы Уруссу Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты**
423950, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы
Пушкин урамы,
38 тел. 2-61-502-92-40

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 7 « 17 » 02 2016 г.

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу ш.т.п. территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүдә гражданнарның катнашу рәвешләрен билгеләү турында**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 18 ноябрендәге 69-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу ш.т.п. территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүдә гражданнарның катнашу рәвешләрен билгеләү максатларында **карар бирәм**:

1. Урыссу шәһәр җирлеге территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүдә гражданнарның катнашу рәвешләренең түбәндәгеләр булуын билгеләргә:

эштә һәм көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү;

беренчел янгын сүндерү чаралары алар милкендәге биналарда һәм корылмаларда булу;

янгынны ачыклаганда алар турында кичекмәстән янгын сагына хәбәр итү;

янгын сүндерү сагы килгәнче кешеләрне, мөлкәтне коткару һәм янгынны сүндерү буенча кулдан килгәнчә чаралар күрү;

янгынны сүндергәндә янгын сагына ярдәм күрсәтү;

дәүләт янгын күзәтчелеге вазыйфаи затларының күрсәтмәләрен һәм башка законлы таләпләрен үтәү;

кануннарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт янгын күзәтчелеге вазыйфаи затларына янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлешен тикшереп тору һәм аларны бозуларны булдырмау максатларында аларга караган җитештерү, хуҗалык, торак һәм башка биналарны һәм корылмаларны тикшерүләр һәм тикшерүләр уздыру мөмкинлеге бирү.

2. Карар имзаланган көненнән үз көченә керә.

**Урыссу шәһәр тибындагы поселогы**

**Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы** **Р.Ф. Вәдигуллин**